КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 ноябрь г.Казань № 851

Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Россия инновацион ягулык-энергетика компаниясе» акционерлар җәмгыятенең Әгерҗе муниципаль районында урнашкан һәм дәүләт милкендә булган 1,4311 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:01:150501:95 кадастр саны белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры чыгармасында күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\851.docx